**СОВЕТ**
**Девятернинского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Девәтернә авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

04.10.2024 Девәтернә авылы № 49-1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге Советы 31.05.2023 елның 33-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге Советы карар чыгарды**:**

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Девәтернә авыл җирлеге Советы карары проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм гавами тыңлауларга чыгарырга (1 нче кушымта).

2. Әлеге карар буенча килүче тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

Ганиев Эрнест Энгельс улы - Девәтернә авыл җирлеге башлыгы, Девәтернә авыл җирлеге Советы рәисе;

Моратов Камил Нургаян улы - Девәтернә авыл җирлеге депутаты;

Габбасов Айнур Габделнур улы - Девәтернә авыл җирлеге депутаты;

Камаев Ирек Мулламөхәммәт улы - Девәтернә авыл җирлеге депутаты;

Заһретдинов Ирек Рафаил улы - Девәтернә авыл җирлеге депутаты.

3. Эшче төркемгә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы проекты буенча Әгерҗе муниципаль районы Девәтернә авыл җирлеге Советы депутатларының һәм гражданнарның тәкъдимнәрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге Советы каравына чыгарырга.